**ГЛАВА**
**Кичкетанского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Кичкетаң авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.10.2020 Кичкетаң авылы № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кичкетаң авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлеге башлыгы к а р а р и т т е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кичкетаң торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 29 октябрендә 14 сәг 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорау итеп расларга: «2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кичкетаң торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Гомуми файдаланудагы юлларны төзекләндерү (Кичкетаң авылының Татарстан, Балтач урамнарында авыл эчендәге юлларны ремонтлау өчен вак таш сатып алу һәм кайтарту, Ленин, Барҗы, Татарстан, Полевая урамнарында чокырларны ямау).

2. Су белән тәэмин итү (насос сатып алу).

3. КУН-10 төягеч сатып алу.

4. Урам яктырткычларын сатып алу.

5. Кичкетаң авылы урамнарын кардан чистарту (ГСМ сатып алу).

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Кичкетаң авылы, М.Җәлил урамы, 2 йорт адресы буенча, авыл мәдәният йорты каршындагы мәйданчыкта үткәрергә.

7. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

10.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы З.Р. Нуриев

Совет Кичкетанского сельского поселения
Кичкетаң авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002452
АГРЫЗСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ •